Керәшен сүзе

№ 2

12 март, 1993 ел, татар атнасы

Бәясе ирекле

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМКЕРӘШЕН ГӘҖИТЕ

КАРЕНДӘШКӘ

Җир-йөзендә күпме керәшен бар
Илдә-көндә күпме исәбе?
Кем әйтәлә, нәсел-нәсәбенең
Сау-тазамы тамыры, үзәге?

Карлы-бозлы яңгыр, заман җиле
Бәгыреңне өтеп исәме?
Яман телләр җанга салган яра
Үзәгеңне, әрнеп, өзәме?

Иркә ачып бер утырыйк әле
Эчең бушар, зарың сөйләрсең.

Синдәй эчкерсез зат бүтән юк бит,
Карендәшем, асыл керәшен.

Инде ару гына яшә берук,
Киләүләрең кирләп китмәсен.
Имәндәй нык, таза нәсәбеңнең
Бөреләрен кырау өтмәсен.

Илдә-көндә күпме керәшен бар?
Беркем белми төгәл исәбен.
...Керәшенгә көн килерме бер, дип
Өзгәләнә бары үзәгем...

Ямаш ИГӘНӘЙ

Котлыйбыз!

23 февральдә Чаллы шәһәре талантларының җәй бәйгесе үткәрелде.

Беренче турда чыгыш ясаган 116 җырчының нибары 24е генә икенче турга үтә алды.

"Татар җыры-93" конкурсында беренчелекне шәһәребезнең танылган җырчысы кардәшебез Георгий Бачков яулады. Борынгы көйләрне аерата матур башкаруы белән билгеле Николай Храмов бәйгедә икенче, ә Мария Майорова өченче урынны алды. Георгийга акчалата беренче премия, ә Николай белән Мариягә кыйммәтле бүләкләр тапшырылды. Уңышларыгыз белән ихлас күңелдән котлыйбыз сезне, кадерле карендәшләребез. Ходай алга таба да уңышлардан, исәнлек-саулыктан аермасын. Киләчәктә дә шушылай матур сәнгатегез белән кешеләр күңелен ямьнәргә, тагын да олырак бүләкләр, исемнәр яуларга язсын. Нәселебезне данлаган өчен олы рәхмәт сезгә.

* * *

Шәһәр зыялылары шурасы карары нигезендә 1992 елда Чаллы газета-журналларында басылган иң уңышлы язмаларның авторлары бүләкләнде. Алар арасында "Аргамак" журналының бүлек мөхәррире А.Малов (Я.Игәнәй) та бар.

Ләкесен Ләке дәген...

Сарман районындагы Ләке - керәшен авылларының иң борынгыларыннан санала. Анда 200 дән артык хуҗалык, диләр. Район һәм колхоз җитәкчеләренең керәшенгә карата "игътибарлылыгы" аркасында бу авылга бүгенгә кадәр телефон үткәрелмәгән. Янәшә-тирәдәге дүрт-биш кечерәк керәшен авылларын инде әйткән дә юк. 70 елларда бу авылның фольклор ансамбле бөтен Союзга билгеле иде. Ә бүген ул таркалу алдында. Чөнки гомер буе шушы колхоз байлыгын имеп ятучы элекке район түрәчекләренә дә, колхоз җитәкчеләренә дә керәшен мәнфәгатьләренең поты бер тиен иде. Бүгенге җитәкчеләр дә шул исәп белән яши, күрәсең.

Җырлап-биеп...

Инде хәбәр ителгәнчә, шәһәребездә 1 марттан алып 5 мартка кадәр керәшен мәдәни атналыгы үткәрелде. 5 мартта шәһәр хакимиятенең Концертлар залында аның йомгаклау концерты булды. Анда Тукай районының Борды, Мәләкәс авыллары, Әлмәт районының Кәләй, Менделеев районының Иске Гришкә авыллары фольклор һәм, гаилә ансамбльләре катнаштылар.

КЕРӘШЕННЕҢ РУХИ ДӨНЬЯСЫ БАШКА

Минем шәхси карашымча, күпмилләтле Татарстан республикасы бүген, 1989 елның 5 декабрендә керәшен милли хәрәкәтенең яңадан туу көнендә карендәшебез, танылган җырчы Раиса Тимофееваның бар кешегә дә аңлаешлы һәм катгый итеп: "Керәшенгә дә көн җитте!" дигән сүзләрендәге чиккә кипеп керде. Әйе бу көнне без күз күгәртеп, алты гасырдан артык зарыгып көттек. Күңелебезгә бик күп әйтәсе сүзләребез җыелды. Әмма регламентның артык кысан булуы миңа аларны әйтеп бетерергә ирек бирми. Шунлыктан, иң мөһим мәсьәләләргә генә тукталам. Чөнки чишеләсе "төен"нәребез чиктән ашкан. Шуларның өчесенә тукталырга уйлыйм.

Беренчедән, әгәр съездның төп максатыннан чыгып, этник төркемнәр мөнәсәбәтенең бердәмлегенә һәм эчке гармониялелегенә ирешергә исәп тотабыз икән, ул чагында без сәяси, юридик, социаль һәм конфессиональ /дини/ яктан бертигез дәрәҗәдә һәм бердәй мөмкинлекләргә ия булырга тиешбез. Ә бу яктан алганда керәшеннәрнең хәле сезнең барыгызныкыннан да яман. Беренчедән, алар хәтта үзатамаларыннан да мәхрүм ителгән. 1926 елгы халык санын исәпкә алудан соң /перепись/ мәсәлән, керәшен этнонимы сәяси, гыйльми һәм дәүләт статистик кулланылыштан бөтенләйгә төшерелеп калдырыла. Бүгенге көндә хәтта керәшеннәрнең күпме икәнлеге дә билгесез. Адәм көлкесе бит, тулы бер халык дөньяда бар, яши, ә рәсми исәптә - юк.

Икенчедән, Сталин произволыннан башкалар белән бер үк дәрәҗәдә зыян күрүенә дә карамастан, керәшен халкы бүгенгә кадәр реабилитацияләнмәгән.

Үзатамадан мәхрүм ителү белән бергә, аларның дәүләт һәм ведомство структураларындагы аппаратларын да бетерделәр. Ул гына да түгел, керәшеннең үзенчәлекле мәдәнияте, гореф-гадәтләре, йолалары, теле һ.б. тулысынча юкка чыгарылды. РСФСР Милләтләр комиссариаты каршындагы Бөтенроссия Үзәк керәшен бүлеге һәм вәкиллеге, Татарстанның партия өлкә комитетындагы керәшен секциясе, керәшен мәсьәләләре буенча югары коллегия, мәгариф халык комиссариатындагы керәшен бүлекләре, керәшен нәшрияты, газета-журналлары, күчмә театр, педагогия техникумы, мәктәпләр һәм ниһаять, бөтен керәшен колхозлары бетерелде.

Өченчедән, империя идеологиясе тырышлыгы

(Ахыры 2 биттә).

Көн һәм гамәл

КЕРӘШЕННЕҢ РУХИ ДӨНЬЯСЫ БАШКА

(Башы 1 биттә).

белән җәмгыятьтә шундый стереотип аң тәрбияләнде ки, кайсыдыр милләткә башкалар өстеннән командалык итәргә, ә бүтәннәргә аңа буйсыну өчен шартлар тудырылды.

Ә керәшенгә карата мөнәсәбәт тагын да начаррак булды. Билгеле, әлеге сәясәтне гамәлгә ашыручыларның аны гасырлар буе көчләп урыслаштыруны яисә, ярты гасырдан артык татарлаштыру сәясәтен туктатуда гаме юк иде. Әмма керәшен әлеге җинаятьчел сәясәт аркасында гына җир йөзеннән һич тә юкка чыкмады.

Ул бары тик үз кавеме эченә бикләнде дә, үзенең этник башлангычын саклаган хәлдә, үзбилгеләнү хокукын һәм милли рухын раслый алганга кадәр кысылган җай халәтендә калды. Һәм менә хәзер инде аның күңеленә мөлдерәмә булып тулган рухи хәзинәләре, интеллектуаль энҗеләре фольклор ансамбльләренең фестивальләре вакытында чайпалып түгелә башлады. Шушыларны исәплисең дә, күңелдә бик тә хаклы рәвештә: керәшен мәдәниятен почмакка посырып, без кемне кешелекнең асыл хәзинәләреннән мәхрүм иттек, дигән урынлы сорау туа. Шул ук татарларны, республикада яшәүче бөтен милләтләрне дә түгелме соң? Ә бит бер халыкның рухи хәзинәсе бөтен кешелекнең уртак бәрәкәте ул.

Дүртенчедән, без керәшен этносының дөньяда барлыгын таныйбызмы, юкмы әмма ул бар һәм керәшеннең проблемасы һичшиксез чишелергә тиеш. Әйе, керәшен ул икенче диндәге татар гына, дигән **карашның** ялгыш икәнлеген танырга күптән вакыт җитте инде. Чөнки керәшен бөтенләй икенче, үзенчәлекле гореф-гадәткә, йолаларга, мәдәнияткә ия булган башка төр рухи дөнья вәкиле. Аның үз эчке дөньясы бар, яшәү рәвеше башкача. Ул хәтта коммунизм идеологлары билгеләгән милли, халыкара, ыруглык, җәмгыяти һ.б. этник кысаларга да сыеша алмый һәм берничди тыюларга да, көчләүләргә дә бирешмәгән һәм бирешмәячәк. Билгеле, кайберәүләр минем бу карашларым белән килешмәскә дә мөмкин, әмма бәхәсләрне фән эшлеклеләренә, галимнәргә калдырып, үзебезнең теләкләребезне ачыктан-ачык ярып салыйк. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Без Татарстан фәннәр Академиясендә керәшен мәсьәләләре белән шөгыльләнүче бүлек булдыруны сорыйбыз. Безне мәсьәләнең конкрет хәл ителүе кызыксындыра. Гомуми мәсьәләләрдән тыш, билгеле, съезд аларга карата үз мөнәсәбәтен белдерер. Ә без бүген түбәндәге мәсьәләләрне кичекмәстән хәл ителергә тиеш, дип саныйбыз.

1. Кайсы һәм нинди дәрәҗәдә булуга карамастан, аз санлы милләтләрне, этник төркемнәрне дискриминацияләү закон нигезендә туктатылсын;

2. Барлык этник төркемнәр тулысынча аклансын /реабилитацияләнсен/, аларның дәүләтчел, конфессиональ һәм җәмгыять структуралары яңадан торгызылсын;

3. Аларның, ягъни этник төркемнәрнең, хаксыз рәвештә тартып алынган, дәүләт тарафыннан конфискацияләнгән индивидуаль, кооператив, акционерлык, дини-культ характерындагы җәмәгатьчелек объектлары һәм милке кире кайтарылсын;

4. Этник җәмгыятьләргә һәм хәтта аерым гражданнарга рухи үсеш өчен бертигез шартлар тудырылсын.

Татарстанда һәр халыкның һәм гражданның милли абруен, шәхси хокукларын саклау турында закон кабул итәргә кирәк.

1992 елның 12 апрелендә Казанда җирле керәшен оешмаларының конференциясе уздырылып, анда аларның массакүләм информация чараларын булдыру, милли театрын яңадан торгызу, туган телдә православие динен тоту мөмкинлеген булдыру өчен чиркәүләрне торгызу, Үзәк керәшен-татар мәктәбе бинасын керәшеннәргә кире кайтарып алу турында карарлар кабул ителде. Барысының да эчтәлеген шәрехләп тормыйча гына мин съезд карарлары проектына үзебез тәкъдим иткән карарларны кертүне дә сорар идем.

А.ФОКИН,
КДУ доценты.
Татарстан халыклары корылтаенда ясаган чыгышыннан.

ПИТРАУ КАЙТТЫ АВЫЛГА

Мамадыш яклары, башка кайбер районнар кебек, элек-электән керәшен төбәге булып саналган. Албай, Никифорово, Җөри, Дүсмәт, Кумырык, Уткино, Юкөче авыллары - керәшеннәр генә яши торган иң эре торак пунктлары. Шуларның берсендә - Албай авылында керәшеннәр быел үзләренең милли бәйрәмнәре - Питрау көнен зурлап уздырдылар.

- Алтмышынчы еллар башына кадәр, кача-поса булса да, дини йолаларны, гореф-гадәтләрне тота идек, - ди авыл Советы рәисе Михаил Никифоров. - Аннары ныклап тыйдылар. Берәр керәшен баласын чукындырса, партоешма секретаре партия билетыннан мәхрүм итәлә иде. Янәсе, атеистик пропаганда начар куелган. Керәшен чиркәүләре мәктәпләргә, клубларга әверелде, җимерелде-ватылды... Быел исә халык үзе Питраукөнен билгеләп үтү турында карар чыгарды.

Күрше Балык Бистәсе районына Казаннан артистлар килгән икән. Колхоз идарәсе рәисе Илья Шалдымов алар белән элемтәгә керә. Тегеләр бәйрәмдә катнашырга ризалык бирәләр һәм билгеләнгән көнгә Венера Ганиева, Айдар Фәйзрахманов, Равил Шәрәфиев, Камил Фәйзрахманов авылга килеп тә төшә. Авыл үзәгендәге мәйданга Казанның Мәскәү районыннан, Үсәли, Түбән Сөн, Катмыш авылларыннан күчмә кибетләр килә, Саба, Арча, Балык Бистәсе, Мамадыш районнары сабан туе батырлары күренә.

Дугалары сөлге-тастымаллар белән бизәлгән атларда милли киемнәргә киенгән, көмеш тәңкәләрдән эшләнгән күкрәкчәләр, чулпылар таккан апай-әбиләр гармунга кушылып җырлый-җырлый урам әйләнәләр. Аннары төрле спорт ярышлары, уен-көлке, җыр-биюләр башланып китә, күңел ачулар мәйданнан урамнарга, тыкрыкларга, су буйларына тарала. Шунысы кызык, көн буена сузылган түгәрәк уеннарында, чүпләмнәрдә такмак җырлауда ник бер генә көй ике мәртәбә кабатлансын икән!.. Керәшен хатыннарының күңел түрләрендә гасырлар буе сакланып килгән энҗе бөртекләренең бетмәс-төкәнмәс булуына исең китәрлек.

Әлеге бәйрәмдә сабан туеның шактый үзенчәлекләре сакланган: капчык сугышы, колгага менү, капчык киеп йөгерү... Әмма мәйдан күрке, әлбәттә инде - көрәш! Шушы төбәк шоферы, исемен ишетүгә кайбер көрәшчеләрне мәйданга чыгудан баш тарттыручы Григорий Абрамов бу юлы да сер бирмәде, көндәшләрен берәм-берәм чирәмгә салып, иң олы приз - тәкәне алды. Соңыннан исәпләп карадык: ун ел буе мәйданнарда бил бирмичә алган җитмеш икенче тәкәсе икән Григорийның.

Төнге уникеләргә кадәр авыл үзенең милли бәйрәм хисләрендә яшәде, икенче яшьлеген кичергәндәй булды. "Алга таба сабан туен геп шүшы көндә үткәрербез", - дигән нәтиҗә ясадылар бәйрәмдә катнашучылар.

Шактый чыгымнар сораган Питрау көнен уздыруга Нижневартовск шәһәрендә эшләүче нефтьче якташлары Иван Семенов биш мең сум акча бирде.

З.ХӘСӘНОВ.

ТАГЫ ДА ИШӘЙДЕК

Авыр чакта туганнар, берләшегез, дигән бабаларыбыз. Бүгенге авыр замана моны аеруча таләп итә. Нәселебезне, рухи хәзинәләребезне, тарихыбызны саклап калуның, культурабызны, телебезне һәм динебезне торгызуның кирәклеген инде барыбыз да аңлый башладык. Әнә шуларны истә тотып, халкыбыз берләшә, үзара якыная башлады. Инде әйтеп үтелгәнчә, Чаллы, Зәй, Түбән Кама шәһәрләрендә һәм районнарында карендәшләребезнең оешмалары, җәмгыятьләре төзелгән иде. Күптән түгел аларга тагын берәү - Алабуга региональ керәшен җәмгыяте өстәлде.

...Быелның февраль ае башында Алабугада Алабуга, Менделеев шәһәрләре һәм районнары, күрше Удмуртиянең Грахово районы керәшеннәре вәкилләренең берләштерелгән җыелышы үткәрелде. Анда нәселебез зыялылары һәм олуг эшлеклеләре белән бергә хөрмәтле кунаклар: танылган җырчыбыз Галина Казанцева, республика керәшен этнография мәдәни-агарту берләшмәсе житәкчесе А.В.Фокин Чаллы керәшен җәмгыяте җитәкчесе Анна Асанова, кәсәбәче В.П.Умнов, “Керәшен сүзе“ газетасы учредителе Н.П.Антонов, газетаның баш редакторы А.Н.Малов, Түбән Кама районы газетасы баш редакторы В.Б.Шадрин катнашты.

Җыелышның көн тәртибенә бер мәсьәлә - Алабуга шәһәрендә регионара керәшән җәмгыятен төзү куелган иде. Керәшеннәрнең үткәне, аларның укыту-мәгариф системасы хакында доклад белән Алабуга Дәүләт педагогия институты доценты, Н.Д.Григорьев чыкты. Аның сөйләгәннәре белән газета укучыларыбызны киләчәктә таныштырырбыз.

Менделеевтан килгән карендәшебез, туган якны өйрәнү җәмгыяте җитәкчесе, шәһәр музее директоры В.Н.Соловьев быел җәен Менделеевскида яшәгән шагыйрь Егор Уткин истәлегенә, аның тууына 60 ел тулу уңаеннан, бик зур юбилей бәйрәме үткәрелүе хакында сөйләде.

Җәгүрнең исемен мәңгеләштерү йөзеннән, аның туган авылы Бөрешледә, ул туган йорт нигезе урынына язулы һәйкәл куелган. Шагыйрь исеменә районда әдәби премия булдырылган. Һәйкәлене ачу бәйрәменә Казаннан, Чаллы шәһәреннән, туган районнан шагыйрь-язучылар чакырылган.

Чыгышының ахырында Виктор Николаевич Иске Гришкә авылы мәктәбе музее базасында регионара музей булдыру хакында сүз кузгатты.

Түбән Камада чыга торган “Туган як“ газетасы редакторы В.Б.Шадрин үзенең чыгышында җыелыштагы мөселман кардәшләребезгә мөрәҗәгать итеп болай диде:

- Безнең тырышып-тырмашып үз проблемаларыбызны чишәргә, җан тире түгеп нәсел-нәсәбебезнең бәһасез асыл рухи хәзинәләрен, культурасын саклап калырга тырышып йөрүләребезне кайбер мөселман кардәшләребез милләтне таркатырга йөрү дип хаталаналар. Ялгыша күрмәгез, без һич тә яман уйда түгел, киресенчә, уртак бәрәкәтебезне сакларга, арттырырга дип кенә тырышабыз. Рухи, мәдәни хәзинәсе арткан милләт таркалмый да, юкка да чыкмый, ярлыланмый да, киресенчә байый, көчәя генә ич.

Җыелыш кунагы, шәһәр мәҗлесе рәисе Фәрит әфәнде Фәттахов та үз чыгышында үзара мөнәсәбәтләрне ныгытуга юнәлдерергә кирәклегенә басым ясады.

Аннары ул шәһәр мәҗлесе члениарының Алабуга керәшеннәренә мөрәҗәгатен укыды.

Кардәшебез П.В.Краснов, ул туган як тарихы буенча китап язган икән, үзенең сүзендә керәшеннәр тарихын өйрәнергә, аны халыкка җиткерергә кирәклегенә тукталды.

Удмуртиядән килгән кунак, Вятско-Камск регионындагы “Мари Ушем“ (“Марийлар Союзы“) оешмасы председателе А.И.Исхаков үз оешмаларының эше, шул төбәктәге керәшеннәр белән бергәләп, йола бәйрәмнәре үткәрүләренең гадәткә әйләнүе хакында сөйләде.

Чаллы керәшен җәмгыяте эшләре белән җыелыш кунакларын аның рәисе Анна Асанова таныштырды.

Аннары сүзне Казан кунагы Галина Казанцева алды.

- Күп кенә мөселман карендәшләребез безне мөселманнан чыккан, дип ялгышалар, - диде ул, - безнең беребез дә беркемнән дә чыкмаган һәм чыгарга да җыенмый. Без керәшен булганбыз һәм шулай булып калырга тиешбез дә. Юк, бүленү өчен түгел, ә үзебезнең очсыз-кырыйсыз, бетмәс-төкәнмәс мәдәни, рухи бәрәкәтебезне саклап калу, аны ишәйтү һәм үстерү турында әрнеп өтәләнәбез. Ә бит ул төпсез кое кебек. Керәшен фольклорын гына ал. Җир йөзендә бүтән бер генә халыкта да андый асыл хәзинә бүтән юк! Шушыларны саклап калу, аны яңартып, үстереп халыкка кайтарып бирү, аның рухи хәзинәсен басту турында җан ату татар милләтен бетерергә, таркатырга йөрү була алмый. Шуны асыл хәзинәне саклап калу турындагы үтенеч белән культура министрына кадәр барып җиттек бит инде. Ни кылдылар соң? Берни дә. Чөнки анда утыручылар халык таләбенә саңгырау-чукраклар. Алар безнең халыкта нинди бай рухи хәзинә бар икәнлеген аңлый-төшенә алырлык дәрәҗәдә түгел. Алай гына түгел, кайбер мөселман кардәшләребез дә моны аңларга теләми. Керәшеннең бер генә халыкка зыян китергәне, бер генә авыр сүз әйткәне, беркемне кыерсытканы, беркемгә каршы корал күтәреп чыгарга җыенганы юк, ләбаса. Үз рухи байлыгыбызны саклап калырга мөмкинлек, керәшен булып яшәү өчен ирек кенә кирәк.

Алабуга шәһәр хакимияте вәкиле, администрация башлыгы урынбасары И.Галимовның чыгышы шәһәрдә керәшен балалар бакчалары ачу, татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү хакында булды.

Казан кунагы, бөтентатар конгрессы башкарма комитеты члены А.В.Фокин керәшен мәсьәләсендә хәл ителергә тиешле бурычларга тукталды.

Милли мәҗлес каршында фән, мәгариф һәм мәдәният буенча ачылган керәшен подкомиссиясе эшләренең барышы белән таныштырды.

А.П.Сихаев керәшен авылларының бетерелүе хакында ачынып сөйләде.

Сугыш елларында оешып, үз-үзен саклап калган Үтәгән авылын тормышлар рәтләнгәч, колхозларны эреләндерү чорында юкка чыгардылар. Мондый авылларның саны исәпсез-хисапсыз, - диде ул.

Әмма шуңа да карамастан, бу сәясәтнең фаҗига икәнен дә аңлаучылар табылды. Шундыйларның берсе, Шүрнәк авылы председателе В.А.Захаров булды. Хөкүмәт тарафыннан кубарылган кыяметтән ул үз авылын исән-имин алып чыга алды.

Җыелыш һәр төбәк вәкилләренең ризалыгы белән Алабугада региональ культура агарту, керәшен җәмгыяте төзү тәкъдимен хуплады, аның Уставын тикшерде һәм кабул итте. Шулай итеп, Алабуга шәһәрендә Татарстанның Алабуга, Менделеев шәһәр һәм районнарының, Удмуртиянең Грахов районы керәшеннәренең яңа, региональ культура-агарту җәмгыяте барлыкка килде. Шунда ук аның идарә составы, члениары сайланды. Җәмгыять председателе итеп Людмила Михайловна Григорьева, аның удырбасары итеп А.П.Сихаев расланды. Юлыгыз уң, игелекле булсын, карендәшләр!

А.МАЛОВ.



"Исәнме, яз!.."

БЕЗНЕҢ ИЛ — САНДУГАЧ САЙРАР ҖИР...

Минем кан кардәшләребез керәшен белән кызыксынуым студент чакларда, аларның гаҗәеп матур “Әкрен кирәк, иплән кирәк, ишетергә сандугач сайрауларын“ дигән җырлары таралган вакытлардан башланды булса кирәк. Моңача без белгән җырларга хас булмаган моңы, үзгәлеге белән җәлеп итте ул күңелләрне. Соңыннан тарихыбызның иң борынгы катламнары - “Өркемәгән кошлар иле“ (Ш.Мәннур сүзләре) Себер якларында сакланган “Кара елан“ җырын Галина Казанцева: “Бу безнең керәшен җыры ич“ дигәч, кардәшләк җеп очлары тагы да тирәнрәк ята, дип уйладым.

Безнең тирәдә керәшен авыллары юк. Гомумән, Себер өлкәләрендә берән-сәрән урнашкан керәшен авыллары булуын гына ишетә белә идек.

Шулай, чын керәшен авылына барып төшүем фольклорчы булыр өчен аспирантурага кергәч, моннан нәкъ 30 ел элек Куйбышев (Самар) өлкәсенә фольклор экспедициясе оештырганда булды. Фәннәр академиясе Тел, әдәбият, тарих институтында сүз һәм музыка фольклоры бер секторда, Хәмит ага Ярми кул астында өйрәнелә иде. Мәхмүт Нигъмәтҗановның да керәшен музыкасын төрки бабаларыбызның иң борынгы архаик асыл элементлары дип санаган чаклары. Хәзер ул архаиканы Себердә таба бугай ул. Без, ел саен үткәрелә торган фольклор экспедицияләрнең бер төркеме булып, 20 килограммлы магнитофон һәм чемодан күтәргән Альберт Йосыпов, Халидә апа Гатина Назаровка авылына барып төштек. Шынталы ягы ул, батыр диңгезче Әсгать Җиһаншин туган як.

Назаровка шул “Әкрен кирәк“тәге моң кебек, хуҗалык ягыннан җилпучлары, карбазлары, келәттәге баллары, баздагы майлары һ.б. белән мул тормышлы борынгы керәшен авылы булып истә калган. Ә инде йорт эчендәге үзгәлекләр: сурәтле, дәүәтле киемнәрен киеп фотога төшүләр дисеңме, ул өстәлгә утырганда аны-моны уйламыйча иконалар астына барып утыргач, хуҗа Җәүдәк әбиебезнең җай гына “кызым, төре почмагына ир-атны утыртыгыз“, диюе булсынмы, гаҗәпләндерә, сәерсендерә иде. Җәүдәк әбинең үзенең дә сул кулын күкрәгенә куеп, уңына ияге белә таянып, безгә карап утыру күз алдымда: “Хәйраннар калам, тормыш ничек үзгәрде. Менә сез, татар кызлары, ир-ат янында яланбаш утырасыз. Элек без татар авыллары аша үтсәк, кызлар капка ярыгыннан гына карап калалар ые“.

- Соң бит, сез дә татар, - дим мин.

- Татар да, без бит керәшен, безнең дин башка, - ди ул.

Мул тәгамле олы табыны, моңлы-җырлы мәҗлесе (алар шулай диләр) күптән түгел генә булган бер өйдә җыр язып утырабыз. Хуҗа ханым безне дә сыйлый, сөйли дә, җырлый да. Оста хор булып, кемнең кем белән тавышы килешкәнен бик яхшы белеп торалар керәшен авылларында. Мамадыш ягы Дүсмәт, Владимировкаларда, башкаларында шулай.

- Рәхәтләнеп, җырлаштыгызмы? - дим.

- Ул гынамы! Әле кунакларны озатканчы таңнар атты. Ирем: “Әйдә су буена төшеп, кояш чыкканны карап кайтыек“, ди. Яшь чактагыдай кулга кул тотышып, “Син сугышка китүче егетләрнең теге җырын беләсеңме, хәтерлисеңме?“ - дия-дия, су буйлап җырлашып йөрибез - ди ул.

Исемнәрен онытгым, сау-таза булсалар, сәламемне ишетсеннәр бу бай җанлы, бәрәкәтле гаиләләргә.

Назаровкадагы кебек бай рухлы, нечкә күңелле, җыр-көйгә мөкиббән киткән керәшен кардәшләребезне күрер өчен җир читендә диярлек, Иркутск өлкәсе Алар районы Харют авылы, Новосибирск өлкәсе Северный районы Кече Кызылъяр авылларына фольклор экспедициябезне бормый үтми идем.

Ә менә Красноярск, Кемерово, Омск, Төмән өлкәләрендә дә шулай ялгыз утырган керәшен авылларына җитә алмадым. Изоляциядән халык рухи байлыкны яхшырак та саклый торган була, яшь белгечләргә соңармаска иде.

Харютта да, Кызылъярда да безне мәҗлесләр җыеп, көе килгән кешеләр бергәрәк утырып, көнетөне җырлашып, күңел җәүһәрләрен тапшырып калдылар. Без аларны 12 томлык фольклор җыйнамасына керттек. Мин язмаларымны ансамбльгә дә, башкаларга да тапшырдым, тик әлегә тиешенчә яңгыраганнарын керәшен фольклоры фестивальләрендә генә ишетәм бугай. Үзебез экспедицияләрдән кайткач, “Айлар, айларым, туганайларым“, “Әйдә китик Сарапулга сары ат исән чагында“ларны яратып җырлаша идек. Ул җырлардагы аерым нәзакәтлелек, ачык күңеллелек, табигатьне олылау әсир итә, җанны билән ала. “Исемнәрең матур кемнәр куйган?“ дип керәшен көенә җырласалар никтер ул нәкъ сиңа атап җырлана сыман, игътибар, якын итү мөгамәләсе ачык сизелә.

Ә инде туй, кодалар җырларының кайсын гына алма, яңарак туганлашкан гаилә-дусларның берберсенә ниндидер тирән ихтирам, теләктәшлек, игелекле аралашуарга омтылуы күренеп тора.

Кергәннәрдән бирле карап торам, Сез икәнсез адәмнәр солтаны - җырын күптән түгел Америка татарлары Илдар әфәнде Агиш, Илхан әфәнде Айдагөлнең Казанга килү уңае белән искә төшердем. Аларның мәчеттә, “Җомга көн кич белән“ тапшыруында булуларын телевидениедә, Татар иҗтимагый үзәге, “Ватан“ җәмгыяте оештырган очрашуда күргән совет татарлары саф татар телен һәм рухын саклап, мәдәниятле, динле булуларына шаккаттылар бугай.

- Әйбәт кенә дисеңме? Адәмнәр солтаны! - ди Киевтан шулай ук уразага кайткан Хәдичә ханым Мусина. - Менә без дип, читтәге татарлар рухын, кыяфәтен, теләкләрен шулай акыллы, матур белдерәләр алар.

Мин алар белән моннан 5 ел элек килүләрендә һәм үзем Америкага барганда танышкан идем. Каршы алып, кунак итеп тә калдык. Китәр алдыннан вакытлары гаять тыгыз булуга карамастан, алар Урманче өенә килеп саубуллашмыйча, Коръән укымыйча китә алмаганнар. Менә ул стереотип, гасырлар буена тупланган, изоляциядә яхшырак сакланган милли чырай, кыяфәт, йолалар.

Америкадагы татарлар әлбәттә тел һәм диннәрен генә яхшы саклый алганнар, бала чакта өйрәнгән күпмедер җыр, көйләрне дә хәтерлиләр. Шуңа да алар татар моңын, татарча Коръән мәкамен ишетергә теләп монда киләләр. Аларны эфир аша тотып, кассеталарга язып та өйрәнәләр. Ә театр, әдәбият, сынлы сәнгать кебек рухи байлыгыбыздан аерылган, мәхрүм алар.

Ул кыяфәт саклануына дин әһәмияте телнекеннән дә артык түгел микән әле. Әнә бит Литва, Польша татарлары телләрен дә җуйган, ә диннәрен саклаганнар. Корылтайга килгән бер Литва татары 600 ел буе диңгыз ите капмаганнарын, намаз-нияз, мөселман йолаларын ташламаганнарын горурланып, русча сөйләде. Кем белә, Коръән тәрҗемә ителгән булса, телләр белән бергә бәлки ул да югалган булыр иде.

Ә керәшеннәр татар эчендә торып, телне дә яхшы саклап, шундый диаспорага әйләнмәгәйләре. Алар да бит театрда үз тормышларын, китапларда үз хәятләрен, гореф-гадәтләрен күрергә, балаларын үз дәреслекләре белән укытырга һәм үз дин сабакларын бирергә телиләр (керәшенлекләрен сакларга теләүчеләр, әлбәттә). Моннан бер-ике ел элек узган керәшен фестивале фәнни конференциясендә Галина ханым Казанцева бик акыллы рәвештә болай дигән иде: “Без татарлыгыбызны югалтырга түгел, керәшенлегебезне сакларга телибез“. Шуннан башка ничек әйтәсең?

Әнә бит Гәрәй Рәхим язып алган дәмәкләрдә халыкның гасырлардан килгән малчылык кәсебесугым сую йолалары ничек шигърияте тасвирлана. Әсәрдә язылганча, чалуга дөрес әзерләнмәгән, тынычландырылмаган дуңгыз чинавы мөселманның гына түгел, христианның да җанын биздерә. Ә мөселманлык ислам диненең көче, чагыштырмача, тиз арада үсеш алуы, минем белүемчә, шул башка диннәргә карата түземлелек, ихтирам, бергәлек саклауда. Бервакыт чын мөселман, карт Урманченең ничек җаны әрнегәнен белсәгез. Шул ук Гәрәйгә Илдар Юзеев бер эпиграмма язган:

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр керосин.
Кулларыңа тәре тотып
Төшләремә керәсең.

Илдар да яшь чагында шаярткандыр, Гәрәй дә игътибар итмәгәндер, артык. Бакый ага аларның икесен дә ярата иде. “Тупас, ярамый алай“, - дип көенеп йөрде.

Ярамый шул менә хәзер дә керәшен туганнарны гомуммилли мәдәни үсештән аерып, гаҗәеп матур фольклорларын, үзенчәлекле этнографияләрен саклау белән генә чикләнергә. Болар турында керәшен вәкилләре корылтайларда сөйләргә тырышалар. Тик 5 әр генә минут сөйләү вакытында сүз алып, фикерләрне тәмамлатмый төшерүгә үпкәләп йөриләр. Әле залдан: “Кайтсыннар мөселманлыкка!“ кебек җиддиятсез шигарьлар да ташланса, әлбәттә, күңелләре төшә аларның. Булмый ул алай гасырлар буе салынган стереотипны вату, җимерү!

Җәүдәк әби әйтмешли, “без бит керәшен“, янсә Георгий Ибушев әйтүенчә, “без бер алмагач ботаклары“. Башка төрки халыкларының да христиан динендәгеләре бар: казах, гагауз, ... гарәпләрнең үзләренең дә христианнары (коптлар) гарәпнең бик үзенчәлекле бер этник кавеме булырак кына билгеле.

Үз илендә, татар җирендә генә бүгенге хәлдә булса да, саклана алуына себердәге керәшен авыллары мисалы ышандыра: урыслар белән аралашырга тел башка, татарлар белән - дин башка. Әле себер татарлары белән тел аерымлыклары да шактый булганча, элек күчеп килгән керәшеннәргә бик кыен булган анда.

Сүземне искиткеч матур “Безнең ил“ җыруы белән очлыйсым килә.

Безнең ил уйнар-көлер җир лә,
Безнең ил сандугач сайрар җир.

Бер алма агачының шау чәчәктәге әллә ничә ботагы булып яшәргә насыйп булсын иде безгә гомер-гомергә.

Мәләкәс авылы - талантларга бай-як. Биредәге Никифоровлар гаилә ансамбле һәр бәйрәмнең йөзек кашы булып тора. Бу рәсемдә сез Анастасия түтине, Анатолий Николаевичны, Римма Михайловнаны, яшьләрдән Николайны, Валераны һәм Иринаны күрәсез.

С.СӘГЫЙРОВ фотосы.

Флора ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ.

● *ИСӘНЛЕК-САУЛЫК ТЕЛИБЕЗ*

"ҺӘЗА КИТАБЕ-Т-ТЫЙБУ"ДАН

Атаклы шәрыкъ галиме, философ, табиб Әбүгалисина (Европача әйтелештә Авиценна) безгә кадәр ун гасыр элек, 980-1037 елларда яшәгән. Аның "Табиблык фәне кануны" дип аталган һәм биш өлештән торган энциклопедик хезмәте борынгы грек һәм римлыларның, шәрыкъ илләре, шул исәптән Һиндстанның, медицина өлкәсендә күп гасырлар буе туплана килгән бик күп казанышларын үзенә сыйдырган. Бу хезмәтнең ике томында 785 төр үсемлек, терлек һәм минералның шифалы хасиятләре тасвирлана. Аларның күбесе хәзерге медицинада да киң кулланыла. Түбәндә шулардан кайберләре китерелә.

КАНӘФЕР (крөнчеп). Иследер, корыдыр, авыз эчен хуш кылыр. Күзнең күргән үткен кылыр, вә тәсне күркәм кылыр, вә күзнең караңгылыгына (катаракта) файдалыдыр. Тамакка ашарга һәм сөрмә итеп күзгә тартырга. Вә янә эч авырткannan файда бирер, вә эчне куәтле кылыр, вә бәгырьне куәтле кылыр, вә косудан, күңел болганганнан файда бирер.

Авызда чәйнәлер вә дәхи борыч кебек ашка салыныр. Төеп он кебек ясап, ярты мыскал (2,13 грамм) кадәрене сөткә салып, ач карынга икешәр тапкыр эчелсә шәһүәтне (ирләрнең җенес әъзасы) куәтле итәр.

Авызда бераз чәйнәлсә, кан кара булганда бозыклыкны китәрер. Күңелне шат кылыр вә эчтәге әгъзаларны барчасын да куәтле кылар, эчтәге усал юешлекләрне киптереп, усал җилләрне китәрер вә тәгамне сеңдерер. Вә теш итләрен (уртларны) нык итәр. Авызда бераз чәйнәлсә, хасил булган томауны бетерер.

СӨТ (ләбн). Сөтләрнең яхшырагы сыер сөте вә һәм яшь сыер сөтедер. Карт вә арык сыерның сөте яхшы түгелдер. Сөт эчү тәсне күркәм кылыр, вә дәхи шикәр белән эчелсә, бигрәк тә күркәм кылыр, вә симез кылыр. Сөтне эчү вә сөртү сипкелне китәрер.

Әмма эчтә шешләре булган кешегә сөт бик яхшы булмас, вә дәхи сеңерләргә яхшы түгелдер. Картлыкта хәтер йомшаруына сөт бер дәвадыр. (Вә дәхи сөт тешләргә зарарлыдыр, теш итләрен бик зәгыйфь итәр: сөт эчкәннән соң авызны вә теш уртларын төче бал белән чайкау бик яхшы). Сөт башы шаулаган кешегә зарарлыдыр. Сөлне эчү күзне караңгы кылыр. Әмма авырый торган күзгә сөт саусалар, бик яхшы булыр. Кәҗә сөте бирән зәхмәтеннән (шикәр авыруы) вә ютәлдән бик файдалы, вә кан төкергәнлеккә бик яхшыдыр, вә сөт үпкәдәге булучы кабырчыкларның (туберкулезның) даруыдыр. Авызга алып, гыргыр итеп чайкалса, тамактагы бакалар (ангина) булганлыктан вә каз тамактан (фарингит) шифасы булыр. Вә сулыш тарлыктан, вә күкрәк авыруыннан файдалыдыр. Вә дәхи сөт суыкның юлын бикләр, вә аның сары зәхмәтенә файдасы бар. Кәҗә сөте бавыр зәхмәтенә, вә тамакның катылыгына файдалы. Вә сөт шәһүтне бик куәтле кылыр. Әмма сөт бизгәк зәхмәтле кешегә зарарлыдыр. Сөт һәртөрле агулардан файда бирә. Тилебәрән орлыгы ашап агуланган кешене сөт әчереп костырырга.

ХӨРМӘТЛЕ КАРЕНДӘШЛӘР!

"Керәшен сүзе" газетасы бүгенге көндә керәшеннәр тормышын һәрьяклап яктыртучы һәм алар мәнфәгатен яклаучы бердәнбер газета. Ул республика каталогына кертелгән. Аның индексы - 54152.

Быелның 15 мартыннан башлап Татарстандагы барлык элемтә бүлекләрендә дә аңа язылырга була. Ярты елга язылу бәясе 522 сум.

"Керәшен сүзе"нә язылыгыз!



ИҢ КИРӘКЛЕ ГАЗЕТАБЫЗ

Арумысез, кадерле "Керәшен сүзе" газетасы редакциясе!

Мин үзем дә керәшен нәселеннән. Башкортстанның Бакалы районы, Өмир (Умирово) авылында туып үстем. Хәзер Октябрьский шәһәрендә яшим. Беренче класстан алып унынчыга кадәр урысча укуым сәбәпле, татарча, сөйләм теленнән башка, аз беләм.

Телевизордан очраклы рәвештә генә "Керәшен сүзе" газетасы оештырылуы турында белдем. Бу безнең өчен иң кирәкле газета! Без бит үзебез хакында да тулклы гына берни дә белмибез, кемнәр без, кайчаннан барлыкка килгәнбез һ.б. Барысы турында да тәфсирләп беләсе килә бит.

Үземә килгәндә, мин ул газетага теләсә нинди бәягә дә язылырга әзер. Аны башкаларга да таратачакмын.

Сәлам белән,
Любовь Григорьевна
СӘЕТГӘРӘЕВА.

ИГЪТИБАР! Акчалата ярдәм итәргә теләүчеләр өчен хисап номеры түбәндәгечә:
Набережночелнинское этнографическое культурно-просветительное общество кряшен.
Р/счет N2700903. Кор счет N 700161148 в ГКБ Автоградбанк Комсомольск. РКЦ МФО 265469.

СЕЗ БЕЛӘСЕЗМЕ?

Россия Федерациясе Югары Советының бер сессиясен үткәрүгә генә дә 252 миллион сум акча тотыла. Әгәр тегә яки бу мәсьәлә регламентка сыеша алмыйча чишемичә калса - һәр көн үркәрелгән утырыш 40 мең сумга төшә.

Моңардан тыш Югары Совет сессияләр барган вакытта тәртип саклау өчен Россия эчке эшләр министрлыгының һәм Оборона министрлыгының махсус сакчылыгыннан файдаланыла. Бу исә чыгымнарның тагын да артуына китерә.

***

Нәселебезнең атаклы каһарманы Брест крепосте оборонасы командиры легендар Петр Гавриловның батырлыгы алдында баш иеп, фашистлар аны хәтта үлем җәзасына тартырга җөрьәт итмиләр.

***

Севастополь оборонасы командиры генерал Новиков белән дә шундыйрак хәл була. Ул узып барганда бервакыт фашист концлагеры начальнигы аягүрә катып честь биреп кала.

Ырым йоласы, имләү

КОТ КОЮ

Имче куркудан хасталаган (чирләгән) кешене табуреткага утырта да аның чишелгән изүе аша тәненә тидермичә, сак кына идәндәге сулы чүмечкә эрегән кургаш коя. Кайчагында имче сулы чүмечне авыруның баш очында тота. Кургаш булмаса шәм балавызы да ярый. Кургаш яки балавыз суда нинди рәвешкә керсә, хаста шул әйбердән курыккан дип уйланыла. Аннары әлеге сурәт билгеле бер вакыттан соң төшеп югалырлык итеп, хастаның күлмәгенә тегеп куела. Кот кайтару өчен имче түбәндәге имырымны әйтә:

Кер котым кер,
Ишектән дә кер,
Тишектән дә кер,
Ат булып кешнәп кер,
Сыер булып мөгрәп кер,
Каз булып какылдап,
Үрдәк булып бакылдап...



Соңгы суык, соңгы сыкылар...

Баш редактор
А.Н.МАЛОВ

Хатлар языгыз:
423805, Татарстан,
Чаллы шәһәре,
Хәсән Туфан
проспекты, 23. п/я 39.

* * *

Телефоннар: 53-30-74,
58-51-75.

* * *

Авторларның фикере редакция фикере белән тәңгәл килмәскә дә мөмкин.

* * *

Татарстан информация һәм матбугат министрлыгында 211 нче номер белән теркәлде.

* * *

Учредитель
Николай Павлович
АНТОНОВ.

* * *

Тираж 6000 данә.
Заказ N 1.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "КАМАЗ" акционерлык җәмгыяте нәшрияте типографиясендә басылды.

* * *

Нәшер итте: "КАМАЗ" акционерлык җәмгыятенең газета-журнал нәшрияте.
Адресы: 423815, Татарстан, Чаллы шәһәре, Шишкин бульвары, 8(30/24)

* * *

Басарга кул куелды: график буенча 2.02.93. 14.00 сәг.
чынлыкта 1.02.93 16.00 сәг.



Ай караңгы булып торса - һава юеш, җепшек булыр, әгәр ачык булып ялтырап торса - һава коры булыр.

Ай очы белән туса, көннәр явымлы булыр.

Ай утырып туса, аяз була.

Айның дүртенче көнендә һава ничек булса - ай буе шулай булыр.

Болытлар түбәннән килсә, каты суыкны көт.

Болытлар сирәк булса - аяз һәм салкын булыр.

Ай тирәли таҗ караңгы төстә булса, суык булыр.

Яңа ай чалкан күренсә, бу кыш кар күп булыр.

Яңа айның очлары нәзек күренсә, салкын булыр.

Яңа айның югары башы җәелебрәк, түбән башы урак кебек бөгелебрәк торса, кыш көне айның унбишенә кадәр салкын булыр.

Яңа туган айның баш-башы бик очлы булып, бик бөгелеп торса, суык булыр.

Кыш көне йолдызлар күе күренсә, салкын булыр. Әгәр сирәк күренсә, җылы һәм буран булыр.

Кояш тирәсендә нур түгәрәкләнеп күренсә, буран булыр. Әгәр дә бу түгәрәк кояшка якын булса, аяз булыр.

Кышның төньяк бураннары ашлык җыйганда яңгыр китерер.